СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

**25.08.2015** пос. Октябрьский **55-275**

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының 2014 елның «17» ноябреннән 46-229 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының 2014 елның «17» ноябреннән 46-229 номерлы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. 2 пунктта:

а) 1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары. Ставка салым түләүчене сайлау буенча бер гаражга яисә машина урынына карата билгеләнә";

б) 4 пунктчасында икенче һәм өченче абзацларны төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«6) Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата 2015 елда 1,5 процент, 2016 елда 1,8 процент, 2017 елда - 2 процент һәм аннан соңгы елларда; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары.»;

1.2. Карарны түбәндәге эчтәлектәге 3 пункт белән карарны тулыландырырга:

«3. Ике фатирдан торган күп фатирлы торак йорттагы фатир милекчеләренә ташламаны әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясенең процент өлеше буларак билгеләнә торган салым суммасын киметү рәвешендә билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу чакта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аны исәпкә алмыйча арта алмый.»;

1.3. 3 һәм 4 пунктларны 4 һәм 5 пунктлар дип санарга.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге карары текстын яңа редакциядә (1 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм җирлек мәгълүмат стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Совет Рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль
районы Октябрьский авыл
җирлеге Советының 2015
елның 25 августыннан 55-275
номерлы Карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында

1. Октябрьский авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә физик затлар мөлкәтенә салым билгеләү һәм гамәлгә кертү.

2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) 0,1 процент:

гараж һәм машина - урыннар;

хуҗалык корылмалары яисә корылмалары, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан;

2) 0,2 процент:

фатирлар;

бүлмәләр;

3) 0,3 процент:

торак йортлар;

әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса, төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак урыны (торак йорт) булса да керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент:

аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

5) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;

6) 2015 елда – 1,5 процент, 2016 елда-1,8 процент, 2017 елда-2 процент, алдагы елларда-Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.

3. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатир милекчеләренә ташламалар билгеләргә, бу фатирның гомуми мәйданындагы утыз квадрат метр салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

4. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым билгеләү турында» 2014 елның «17» ноябреннән 46-229 номерлы Октябрьский авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны җирлек мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов